РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА**

**Кирельского сельского поселения**

***Камско-Устьинского***

**муниципального района**

Улица Гагарина, дом №1, Камско-Устьинского района,
422827, Республика Татарстан
Телефон 8 (277) -367-45.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

***Кама Тамагы***

**муниципаль районы**

**БАШЛЫГЫ**

**Кирельского сельского поселения**

Гагарина Ур, Кама-Тамагы район, 422827,
Республика Татарстан
Телефон 8 (277)- 367-45.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 елның 3 декабре** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегенең Кирельск авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан айдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге Уставы нигезендә **КАРАР бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегенә кергән Кирельск торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының 1 этабын 2019 елның 14 нче декабренә13.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегенә кергән Кирельск торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының 2 этабын 2019 елнын 15 нче декабренә 11.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлегенә кергән Кирельск торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны, түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

- авыл эчендәге һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту;
-җәйге-көзге чорда чүп үләннәрен чабу.

« ӘЙЕ» «ЮК»

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә:
ТР, Кама Тамагы районы, Кирельск авылы, Гагарин урамы, 1 йорт (административ бина);
ТР, Кама Тамагы районы, Кирельск авылы, Гагарин ур., 14 ("Раифа" кибете»)
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кирельск авылы, Түбән ур., 6 йорт (китапханә);
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 3 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кирельск авыл җирлеге”муниципаль
берәмлеге башлыгы Ф.Я.Зиннәтуллин